КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 октябрь г.Казань № 1207

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 380 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 849 нчы; 2016 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2016 ел, 22 июль, 499 нчы; 2017 ел, 15 май, 285 нче; 2018 ел, 2 апрель, 201 нче; 2018 ел, 29 август, 731 нче; 2019 ел, 16 апрель, 296 нчы; 2019 ел, 20 август, 690 нчы; 2020 ел, 27 апрель, 336 нчы; 2020 ел, 13 июль, 578 нче; 2021 ел, 19 март, 147 нче; 2022 ел, 7 март, 204 нче; 2022 ел, 15 апрель, 356 нчы; 2022 ел, 3 июнь, 515 нче; 2023 ел, 6 март, 217 нче; 2023 ел, 29 май, 651 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында халыкны һәм территория-

ләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта:

«чираттагы финанс елына» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

«Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин